Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР

19 сентябрь, 2024 ел № 28

Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 04 апрелендәге 1 номерлы Югары Шөн авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Важашур авыл җирлеге Уставы нигезендә, Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 30 сентябренә 10 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Югары Шөн торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 04 апрелендәге 1 номерлы Важашур авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Шөн авылы, Октябрь урамы, 22а йорты адресында урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлеге Югары Шөн авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге 4 яисә аннан да күбрәк бала тәрбияләүче гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокны хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала,
1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту *(Югары Шөн авылында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);*

*(юлларга вак таш салу, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);*

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм аларга бирелгән мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (*урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм*

*урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм сатып алу, Югары Шөн авылында урам яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре*);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (*спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Югары Шөн авылы спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү *( Югары Шөн авылында янгын гидрантлары, янгын краннары сатып алу һәм урнаштыру, янгынга каршы инвентарь сатып алу, проект-смета документлары)*;

- Югары Шөн авылының традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү *(зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру );*

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау *(су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Югары Шөн авылында су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре)*;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү

*(Югары Шөн авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)*

2024 елның 4 апрелендәге 1 номерлы карарда күрсәтелгән эшләр төрләрен тулыландыру өлешендә түбәндәге эшләр белән тулыландыру өлешендә:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү

*(Югары Шөн авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, төзү (рәтләү) проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)*

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Важашур авыл җирлеге башлыгы: П.Л. Иванов